# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Житештерү һәм куллану
калдыклары турында

Әлеге Закон хуҗалык итү яисә башка эшчәнлек барышында барлыкка килүче житештерү һәм куллану калдыкларының әйләнә-тирә табигать мохитенә экологик зарарлы йогынтысын булдырмый калуга һәм өстәмә чимал чыганагы буларак аларны хуҗалык әйләнешенә мөмкин кадәр күбрәк җәлеп итүгә юнәлтелә.

## I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

**1 статья.** Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр

Калдыклар - әйберләрдән һәм предметлардан көнкүреш-хуҗалык яисә житештерү эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килә торган һәм шул урында кулланылмый калган өлешләр ул.

Калдыклар белән эш итү - калдыкларны җыю, транспортлау, саклау, файдалы эшкә тоту, зарарсызландыру һәм күмү ул, моңа әлеге гамәлләрне тикшереп тору һәм калдыкларны урнаштыру урыннарында хезмәт күрсәтү дә керә.

Калдыкларны җыю - киләчәктә файдалы эшкә тоту яисә урнаштыру максаты белән калдыкларны оешкан тестә җыю, сортларга аеру, әзерләү һәм транспортлау ул.

Калдыкларны транспортлау - калдыкларны саклау, файдалы эшкә тоту, зарарсызландыру һәм күмү урыннарына күчерү ул.

Калдыкларны саклау (туплау) - киләчәктә файдалы эшкә тоту яисә зарарсызландыру һәм күмү максаты белән читкә чыгарганчыга кадәр калдыкларны махсус җиһазландырылган туплагычларда саклау ул.

Калдыкларны файдалы эшкә тоту - калдыкларны икенчел чимал

итеп файдалану ул.

Калдыкларны зарарсызландыру - алардагы зарарлы матдәләрне һәм химик кушылмаларны тиешле концентрацияләрнең иң чик мөмкин күләменә кадәр җиткереп калдыру.

Калдыкларны күмү - калдыкларны киләчәктә файдаланмау нияте белән махсус җиһазландырылган саклау урыннарына урнаштыру ул.

Калдыкларны урнаштыру - калдыкларны махсус билгеләнгән урыннарда оешкан төстә саклау һәм күмү, шулай ук бергә туплау ул.

Калдыклар барлыкка китерүнең лимиты - билгеле бер вакыт эчендә билгеле бер урында калдыклар барлыкка китерү өчен рөхсәт ителгән күләм ул.

Калдыкларны урнаштыру лимиты - калдыкларны билгеле бер вакыт эчендә билгеле бер урында саклау яисә күмү өчен билгеләнгән тәртиптә рөхсәт ителгән күләм ул.

2 статья. Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендәге законнар

Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләр "Татарстан Республикасында әйләнә-тирә табигать мохитен саклау турында" Татарстан Республикасы Законы, әлеге Закон һәм башка закон актлары белән җайга салына.

3 статья. Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүнең төп принциплары

Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүнең төп принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

әйләнә-тирә мохитне, кеше сәламәтлеген һәм гомерен саклауның өстен булуыннан;

җәмгыятьнең экологик һәм икътисадый бердәмлегенең фәнни нигезләнгән булуыннан, аз калдыклы һәм калдыксыз җитештерү процессларын оештырудан һәм гамәлгә ашырудан, ябык технология цикллары нигезендә матди-чимал байлыкларын комплекслы яңадан

218



эшкәртүдән, әйләнә-тирә табигать мохитендә калдыкларны экологик яктан хәвефсез урнаштырудан, беренчел чималны икенчел чимал белән алмаштыру гамәлләрен тормышка ашырудан;

чималларны һәм материалларны нәтиҗәле файдалану исәбенә аларны экономияләүнең зарурилыгыннан, калдыкларны тикшермичә туплау, куллану һәм чыгарып ташлау аркасында әйләнә-тирә мохиткә зарарлы тәэсирне булдырмый калудан;

җәмгыятьнең барлык эшчәнлеге өлкәләрендә барлыкка килүче икенчел матди байлыкларны куллану буенча комплекслы һәм максатчыл программаларны гамәлгә ашыру юлы белән мөмкин кадәр күбрәк аларны файдалануга һәм җитештерүгә җәлеп итүдән.

## П бүлек. Калдыклар белән эш итүнең икътисадый механизмы

### 4 статья. Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүнең икътисадый механизмы

Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүнең икътисадый механизмы түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

җитештерү һәм куллану калдыкларын дәүләт тарафыннан исәпкә алу;

калдыклар белән эш итү өлкәсендәге гамәлләрне төрле финанс чыганаклары исәбеннән үтәүне тәэмин итү;

калдыклар барлыкка килүнең һәм аларны урнаштыруның лимитларын билгеләү;

калдыклар урнаштырган өчен түләү нормативларын билгеләү һәм шулар нигезендә түләүләр алу;

икътисадый кызыксындыру (калдыксыз, аз калдыклы һәм ресурсларны саклаучы технологияләрне гамәлгә керткәндә, калдыкларны икенчел чимал итеп кулланганда салым, кредит ташламалары һәм башка ташламалар бирү һәм башка чаралар);

җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүгә бәйле эшчәнлекне лицензияләү.

5 статья. Җитештерү һәм куллану калдыкларын дәүләт исәбенә алу

Калдыклар белән эш итүгә бәйле предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртип нигезендә бердәм система буенча дәүләт исәбенә алынырга тиеш.

Милек рәвешләренә һәм кемгә буйсынуларына карамастан, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар җитештерү һәм куллану калдыклары барлыкка килүнең һәм алар белән эш итүнең билгеләнгән тәртиптә беренчел исәбен алып барырга тиешләр.

6 статья. Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү программаларын, гамәлләрен планлаштыру һәм финанслау

Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә гамәлләр планлаштыру һәм программалар әзерләү предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең республика һәм җирле органнары тарафыннан башкарыла.

Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү программалары һәм гамәлләре түбәндәгеләр исәбеннән финанслана:

- Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлары;
- предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның үз акчалары һәм инвестицияләре;
- Татарстан Республикасының экология фонды акчалары;
- банк кредитлары;
- халыктан иганә кертемнәре, чит ил юридик затларының һәм гражданнарының ирекле иганә кертемнәре, шулай ук законнар нигезендә башка чыганаклар.

Калдыклар белән эш итү программаларын һәм гамәлләрен финанслау Татарстан Республикасының Республика бюджетында һәм җирле бюджетларда аерым юл рәвешендә бирелә.

7 статья. Житештерү һәм куллану калдыкларын барлыкка китерү һәм аларны урнаштыру лимитлары

Предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар өчен, житештерү һәм куллану калдыкларын барлыкка китерү һәм урнаштыру лимитлары, республикадагы экологик вәзгыятьне исәпкә алып, Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

Житештерү калдыкларын барлыкка китерү буенча билгеләнгән нигезләүләр булмаганда, калдыкларны барлыкка китерү һәм урнаштыру өчен лимит бирелми, бөтен барлыкка килгән калдыклар норматавтан тыш дип исәпләнә.

Калдыклар барлыкка китерүче житештерү процесслары һәм технологияләре әлеге Законны гамәлгә керткән көннән башлап ике ел дәвамында һәм кимендә биш елга бер мәртәбә даими рәвештә экологик аттестация узарга тиеш.

Аттестация нәтиҗәләре буенча предприятиенең калдыклар паспорты эшләнә.

8 статья. Житештерү һәм куллану калдыкларын урнаштырган өчен түләүләр

Житештерү һәм куллану калдыкларын урнаштырганда түбәндәгеләр өчен түләүләр алына:

- билгеләнгән лимит чикләрендә калдыкларны урнаштырган өчен;
- калдыкларны билгеләнгән лимиттан тыш урнаштырган өчен.
- калдыкларны рөхсәтсез туплаган һәм күмгән өчен.

Калдыкларны урнаштырган өчен түләү нормативларын исәпләү һәм куллану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Калдыкларны урнаштырган өчен түләүләр кертү табигатьтән файдаланучыларны табигатьне саклау гамәлләрен үтәүдән азат итми.

9 статья. Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә икътисадый кызыксындыру

Икътисадый кызыксындыру түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

- аз калдыклы, калдыксыз һәм ресурсларны саклаурлык технологияләрне үзләштерүче, калдыкларны икенчел ресурслар итеп файдаланучы предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга законнар нигезендә кредит һәм салым ташламалары, дәүләт дотацияләре билгеләү;

- җитештерү һәм куллану калдыклары барлыкка килүне киметүне тәэмин итүче, калдыклар белән эш иткәндә хәвеф-хәтәрне киметүче башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру.

Милек рәвешләренә карамастан, калдыкларны файдалы эшкә тоту буенча махсус шөгыльләнүче предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар калдыкларны урнаштырган өчен түләүдән азат ителәләр. кредит ташламалары бирү.

10 статья. Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүгә бәйле эшчәнлеккә лицензия бирү

Җитештерү һәм куллану калдыкларын җыюга, транспортлауга, саклауга, файдалы эшкә тотуга, зарарсызландыруга, күмүгә бәйле эшчәнлек лицензияләр (махсус рөхсәтләр) нигезендә генә башкарыла.

Лицензияләр Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләр күрсәтелгән килеш бирелә:

- җитештерү һәм куллану калдыкларын барлыкка китерүнең һәм аларны куллануның төрләре, күләмнәре һәм лимитлары;

- эшчәнлекнең лицензияләнүче төрен гамәлгә ашыру шартлары;

- калдыклар белән эш итүгә куелучы экологик таләпләр һәм аларны үтәмәгән өчен җаваплылык.

Калдыклар белән эш итү хокукы лицензия алган мизгелдән яисә анда күрсәтелгән вакытта барлыкка килә.

Лицензияләр 5 елдан артык вакытка бирелми.

## Ш бүлек
## Калдыклар белән эш итүгә һәм аларны транспортлауга бәйле предприятиеләрне, корылмаларны һәм башка объектларны урнаштырганда, төзүне проектлаштырганда, яңадан торгызганда һәм файдаланганда куелучы экологик таләпләр

11 статья. Житештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүгә һәм аларны транспортлауга бәйле предприятиеләрне, корылмаларны һәм башка объектларны урнаштырганда, төзүне проектлаштырганда, яңадан торгызганда һәм файдаланганда куелучы гомуми таләпләр

Промышленностьтагы, авыл һәм урман хуҗалыгындагы, транспорттагы, энергетикадагы, су, коммуналь-көнкүреш хуҗалыкларындагы һәм башка объектлардагы калдыклар белән эш итүгә бәйле предприятиеләрне, корылмаларны урнаштыру, проектлаштыру, төзелешне техник-икътисадый нигезләү, яңадан торгызу, файдалануга тапшыру әлеге Закон таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Калдыклар белән эш итүче предприятиеләрне, корылмаларны һәм башка объектларны төзү өчен урыннар Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгының, санитария-эпидемиология күзәтүе органнарының уңай бәяләмәсе һәм дәүләт идарәсе җирле органнарының һәм җирле үзидарә органнарының карарлары булганда гына билгеләнә.

Кирәк очракларда, халыкның экологик мәнфәгатьләренә кагылышлы объектларны урнаштырганда, карарлар референдум нигезендә кабул ителә.

Проектларны техник-икътисадый нигезләү һәм калдыклар белән эш итүгә бәйле предприятиеләрне, корылмаларны һәм башка объектларны төзү проектлары дәүләт экология экспертизасы, ә кирәк чакта иҗтимагый экологик экспертиза да үтәргә тиеш. Фәнни коллективлар, иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан алар инициативасы белән уздырылучы иҗтимагый экологик экспертиза нәтиҗәләрен дәүләт экология экспертизасының тиешле органнары карарга

тиеш.

Дәүләт идарәсенең җирле органнары һәм җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар калдыкларны саклау, файдалы эшкә тоту, зарарсызландыру һәм күмү буенча нәтиҗәле чаралар күрергә, калдыклар белән эш иткәндә экология, санитария-гигиена һәм эпидемияләргә каршы гамәлдәге нормаларны һәм кагыйдәләрне үтәргә тиеш.

Калдыкларны файдалы эшкә тоту, зарарсызландыру һәм күмү гамәлдәге нормалар һәм кагыйдәләр нигезендә башкарыла.

Шәһәр һәм башка торак пунктлары территорияләрендә, урман-парклар, курорт, дәвалану-сәламәтләндерү һәм ял итү, су-саклагыч зоналарда калдыклар урнаштыру тыела.

Гомуми кулланылыштагы сулыкларга, сулы җир асты горизонтларына калдыкларны агызу тыела.

Калдыклар белән эш итүгә бәйле экологик яктан зарарлы объектларның эшчәнлегенең юнәлешен үзгәртү Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органнары белән килешеп гамәлгә ашырыла.

<u>12 статья.</u> Җитештерү һәм куллану калдыкларын транспортлауга куелучы гомуми таләпләр

Калдыкларны бары тик махсус җиһазланган транспорт чараларында гына йөртү рөхсәт ителә.

Махсус билгеләнгән урыннардан читтә җитештерү һәм куллану калдыкларын бушату тыела.

## IV бүлек. Калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат һәм фәнни тикшеренүләр

<u>13 статья.</u> Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат

Калдыклар белән эш итүче предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитетына, казылма байлыклар чыгаруны һәм промышленностьны күзәтү ор-

ганнарына җитештерелгән һәм саклана торган калдыкларның микъдары, үзенчәлеге һәм аларны урнаштыру турында тулы һәм дөрес мәгълүмат бирергә тиеш.

Җитештерелгән калдыкларның төрләре һәм үзенчәлекләре турындагы белешмәләрне, әйләнә-тирә мохиткә һәм кешеләр сәламәтлегенә аларның йогынтысы турында, калдыклар җитештерүне киметүгә юнәлтелгән чаралар турында, әйләнә-тирә мохиттә калдыклар барлыкка китерә торган яисә билгеләнгәннән артыграк күләмдә калдыклар китереп чыгара торган бәла-казалар һәм һәлакәтләр турында мәгълүматларны да кертеп, бөтен халык белергә тиеш һәм алар сер итеп сакланырга тиеш түгел.

<u>14 статья.</u> Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә фәнни тикшеренүләр

Галимнәр һәм фәнни учреждениеләр белгечләре калдыклар белән эш итү мәсьәләләре буенча халыкара, федераль, республика, төбәк һәм тармакларның комплекслы максатчыл программаларын әзерләүдә һәм тиешле проектлар буенча эксперт бәяләмәләре әзерләүдә катнашалар.

V бүлек. Калдыклар белән эш итү
өлкәсендә экологик тикшереп тору

<u>15 статья.</u> Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә дәүләт экология тикшереп торуы

Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, шулай ук Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты тарафыннан "Татарстан Республикасында әйләнә-тирә табигать мохитен саклау турында"гы Татарстан Республикасы Законы һәм әлеге Закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

16 статья. Житештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә житештерү экологик тикшереп торуы

Предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның экологик хезмәтләре калдыклар белән эш итү өлкәсендә житештерү буенча экологик тикшереп торуны "Татарстан Республикасында әйләнә-тирә табигать мохитен саклау турында" Татарстан Республикасы Законы һәм әлеге Закон нигезендә гамәлгә ашыралар.

17 статья. Житештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә ижтимагый экологик тикшереп тору

Ижтимагый экологик тикшереп торуны ижтимагый берләшмәләр, гражданнар башкара, аларның бурычлары министрлыклар, дәүләт комитетлары, ведомстволар, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар һәм гражданнар тарафыннан әлеге Закон таләпләренең үтәлешен тикшереп торудан гыйбарәт.

Ижтимагый экологик тикшереп торуны уздыру тәртибе әлеге Закон һәм башка норматив-хокукый актлар белән жайга салына.

VI бүлек. Калдыклар өлкәсендәге бәхәсләрне хәл итү

18 статья. Житештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендәге бәхәсләрне хәл итү

Житештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, гражданнар арасындагы бәхәсләр законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

## VII бүлек. Калдыклар белән эш итү өлкәсендәге законнарның таләпләрен бозган өчен җаваплылык

**19 статья.** Житештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендәге законнарны бозган өчен җаваплылык

Житештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендәге законнарны бозуда гаепле урындагы затлар һәм гражданнар, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар законнар нигезендә юридик җаваплы булалар.

**20 статья.** Житештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендәге законнарны бозу аркасында китерелгән зыянны түләттерү

Калдыклар белән эш итү өлкәсендәге законнарны бозып, әйләнә-тирә табигать мохитенә, гражданнарның сәламәтлегенә һәм милкәтенә, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның милкәтләренә зыян китергән предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар һәм гражданнар бу зыянны законнарда билгеләнгән тәртиптә түләргә тиешләр.

## VIII бүлек. Калдыклар белән эш итү өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек

**21 статья.** Житештерү һәм куллану калдыкларын чик аша йөртү

Житештерү һәм куллану калдыкларын импортлауга (экспортлауга) лицензияләр бирү Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә гамәлдәге законнар нигезендә башкарыла.

Хәвефле (шул исәптән радиоактив) калдыкларны импортлау тыела.

267



22 статья. Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә халыкара шартнамәләр

Әгәр Татарстан Республикасы тарафыннан тәэелгән җитештерү һәм куллану калдыклары өлкәсендәге халыкара шартнамәдә әлеге Законадагыдан үзгәрәк кагыйдәләр билгеләнгән булса, бу очракта халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1997 елның 2 июле
N I243